КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 16 март г.Казань № 219

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2025 ел, 8 сентябрь, 673 нче карары белән расланган «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2025 ел, 8 сентябрь, 673 нче карары белән расланган «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Гомуми, урта һөнәри белем бирү һәм тиешле өстәмә һөнәри белем бирү, балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү, балалар ялын һәм аларны савыктыруны оештыру өлкәсендә инвалидлар өчен объектлардан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алу шартларын тәэмин итү, шулай ук аларга шул ук вакытта кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 31 март, 253 нче боерыгы;»;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары, урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары һәм

тиешле өстәмә һөнәри программалар, һөнәри укытуның төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагог һәм башка хезмәткәрләренең эш вакыты һәм ял вакыты режимын раслау турында» 2025 елның 4 апрелендәге 268 номерлы боерыгы;».

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин